
Кече Лызи гомуми белем бирү мәктәбе
Балтач муниципаль районы ТР



# Фәнни - практик эш

## Тема: «Габдулла Тукай фотосурәттә».

Башкаручы: Федорова Диана Александр кызы
Җитәкче:Фазылҗанова Гөлия Рафаил кызы,
1нче квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

2016 ел.

Актуальлек: Габдулла Тукайның фотосүрәтләрдә йөзенең төрлечә бирелешен ачыклау фәнни эшкә этәргеч булып тора.

Максат: Г.Тукай фотосүрәтләренең фәнни чыганакларда төрлечә чагылышының әдәби асылын күрсәтү.

Бурычлар:

1. Төрле әдәби чыганаклардан Г.Тукайның фотосүрәтләрен туплау.

2. Фотосүрәтләрдәге аермалылыкны һәм охшашлыкны ачыклау.

3. Ачыкланган нәтиҗәләр буенча фәнни эшкә йомгак ясау.

Г.Тукайның бала чактагы фотолары юк, дөресрәге, елы да, вакыты да ул булмаган. Бары тик 1903 елда, унҗиде яшендә генә, объектив каршына баса. Әлеге фото моның дәлиле.



Рәсемдә тәбәнәк буйлы, ак күлмәкле, шәкертләр кәзәкиеннән, башына биек кәләпүш кигән малай фотосын күрәбез. Рәсемгә карап, әлеге шәкерткә унике-унөч яшьләрдер дип уйлыйсың.Ә чынлыкта, бу Г. Тукайның унҗиде яшьлек егет чагы.

1903 ел, Җаек.

1905 ел.     Г.Тукай Камил Мотыгый белән.



Бу фотосүрәткә карата шик белдерүчеләр дә табылган. Ягъни, Тукай түгел, ә бөтенләй таныш булмаган шәкерт диючеләр дә булган. Ләкин, нәкъ  менә беренче һәм икенче фотосүрәттәге Тукай охшаш.Миңа калса, бу бердәнбер очрак.



1906 елда Г.Тукайның кулына журнал тоткан килеш төшкән фотосүрәте сакланган. Игътибар белән карасак, шагыйрьнең уң ягында тагы кемдер булуы сизелә. Бу кеше Камил Мотыйги була.




- 1907 елда төшерелгән фотосүрәтне мин бик озак өйрәндем, карадым, уйландым, икеләндем... Чөнки әлеге рәсемдә Тукай бөтенләй башка. Әйтерсең, безнең алда кара күзлек кигән сукыр кеше утыра.

“Әл-Ислах” нәшрияте хезмәткәрләре. 1908 ел.



- Габдулла Тукайның хезмәттәшләре белән төшкән фотосы.

- Өч дус, өч шагыйрь . Аягын эскәмиягә куйганы – Тукай, Сәгыйт  Рәмиев – уртада, өченчесе – Фәхрелислам Агиев. Өчесенең дә үлеме – иртә, кызганыч үлем.



- 1908 ел.



Г.Тукайның төрле фәнни-әдәби чыганакларда иң еш очрый торган фотосы дисәм дә ялгышмам. Чөнки әлеге фотосүрәттә шагыйрьнең тулы, түгәрәк йөзле, чибәр, зәвык белән киенгән вакыты. Әлбәттә, бу фотографның тырышлыгы нәтиҗәсе. Чынлыкка туры килмәсә дә, Тукайның үзенә фотосүрәте бик ошаган.

Якынча 1910 ел.



- Әлеге фотосүрәттә Г. Тукай фуражкадан. Ул малайлар сыман. Шагыйрьнең кечкенә, ябык гәүдәсе аны гел баласытып күрсәтә. Бу фоторәсем күп чыганакларда очрый, ләкин тулы форматта түгел.

- 1911 ел.

- Шулай ук 1911 елгы фоторәсем. Г.Тукай, С. Рәмиев һәм Шәхид Гайфи лодкада утыралар. Ш. Гайфи Әстерханда Г. Тукайны оештыручы һәм урнаштыручы буларак билгеле шәхес. Бер елда төшерелгән фотолар булса да, алар арасындагы аермалылык күзгә ташланмый калмый.






Әстерханда дәваланып кайтканнан соң, төшкән әлеге рәсемдә Тукайның кәефе һәм сәламәтлеге яхшырган чак. Шуңа күрәдер ул монда чибәр, тулы йөзле, таза күңелле булып сакланган. Киемнәренең зәвыклыгы, байлыгы нәшриятчы Борһан Шәрәф тырышлыгы.

1911 ел.

1912 елгы фоторәсемдә Г. Тукайның йөзендә аз гына елмаю сизелә. Әгәр ялгышмасам, бу аның бердәнбер фотосы. Башкалары белән чагыштырсак, шагыйрь монда бөтенләй үзгә. Алдагы фотосүрәтләрдән аермалы буларак, без аны мыеклы килеш күрәбез. Тукай йөзенә тагы бер яңалык, үзгәреш.



- Бер ел эчендә өч фотосурәт ясала, һәм бер-берсенә һич охшаш түгел. Габдулла Тукай абыйлы-энеле Коләхметовлар һәм Фатих Әмирхан белән. Тукай йөзендэ балалыкның эзе дә юк. Ул ир-атлар рәтендә атлый. Ләкин бик аз...




- 1912 ел.



- Әлеге фоторәсемдә Габдулла Тукай чын акыл иясе: киң маңгай, кәкрерәк борын, таләпчән, кисәтүле караш. Ул тиздән безнең арадан китәчәк, моны үзе дә сизә, тоя, белә. Ләкин, кем аның эшен дәвам итәр?..

- 1912 ел.

# Клячкин сырхауханәсе. Соңгы сулыш.



- Габдулла Тукайның безгә килеп җиткән, сакланган фоторәсемнәренең соңгысы. Бер тәүлектән Тукай безнең арадан китәр. Дуслары араларыннан китүче бөек шагыйрь белән истәлеккә фотога төшәргә булалар. Ләкин, ни кызганыч, дуслары рәсемнән юк ителә.
  - 1913 ел.

# Габдулла Тукайның үлеменнән соң ясалган маскасы.



- Бөек шагыйрь  үзенең халкы өчен көченнән килгән  барысын да эшләгән. Бу маскада без көчле рухлы акыл иясенең йөзен күрәбез.

- 1913 ел.

# Кулланылган әдәбият


- 1. Казан журналы, 7-2006,  Душа народа в творчестве Габдуллы Тукая.
- 2. Ибраһим Нуруллин, Риф Якупов, Тукай турында хатирәләр.- 1976, Татарстан китап нәшрияты.
- 3.  Габдулла Тукай. Избранное. Магариф.- 2006, Казань.
- 4. Интернет портал www.gabdullatukay.ru